ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2021 Баулы шәһәре №55

«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге Башкарма комитетының
«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге
территориясендә стационар булмаган
сәүдә объектларын һәм җәмәгать
туклануы объектларын урнаштыру
тәртибе турындагы нигезләмәне раслау
турында" 2021 елның 24 февралендәге
20 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" 2021 елның 24 февралендәге 20 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Баулы шәһәре» муниципаль

берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруның аерым мәсьәләләре турында нигезләмә;

- 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруның аерым мәсьәләләре турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль милектәге җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

- 1.4 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

- 2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

- 4.2 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

- 4.15 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.15. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштырган өчен түләү алына, аның күләме «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары һәм әлеге карар нигезендә билгеләнә.»;

- 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ инициативасы буенча (килешү буенча) стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карарының 2.2.3, 2.5 пунктларында каралган очракларда бер яклы тәртиптә өзелергә мөмкин.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты
җитәкчесе Д.Л. Бакиров